**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 30 декабрь № 1077

г. Казань

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесен төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының гамәлдәге «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт бюджет учреждениесенең төрен үзгәртү юлы белән, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт бюджет учреждениесенең төп эшчәнлек максатларын һәм иң чик штат санын саклап, «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесен төзү турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы башкара;

«Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт казна учреждениесе эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына бюджет турында Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы» ведомствосы буенча каралган акча исәбеннән бюджет сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына 60 көн эчендә «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Аппараты» дәүләт бюджет учреждениесе уставына әлеге карар нигезендә үзгәрешләр кертергә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\1077.doc